**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының**
**Якты күл авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**24.07.2026 ел** **№ 28**

**Зәй муниципаль районы Якты күл авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты күл авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 29.12.2020 елның 18 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Конкуренцияне яклау турында "Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2025 елның 29 декабрендәге 577-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районының Якты күл авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Якты күл авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Зәй муниципаль районы Якты күл авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты күл авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 29.12.2020 елнын 18 номерлы карарына (Зәй муниципаль районының Якты күл авыл җирлеге Советының 20.04.2021 № 29, 04.03.2022 №53, 23.11.2022. № 78, 06.03.2023 №93, 18.10.2024 № 140, 18.06.2025 № 169 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 5.13 пункытны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.13. Шушы Нигезләмәнең 5.3 пунктының икенче абзацында билгеләнгән очракта аукцион җиңүчесе йә аукционның бердәнбер катнашучысы дип танылган зат белән сату-алу килешүе төзү "Интернет" челтәрендәге рәсми сайтта аукцион йомгаклары турында беркетмә урнаштырылган көннән алып ун көннән дә иртәрәк һәм егерме көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла. Муниципаль мөлкәтне гавами сервитут һәм (яисә) 21.12.2001 елгы 178-ФЗ номерлы Федераль законда һәм (яисә) башка федераль законнарда каралган чикләүләр белән йөкләгән очракта, аукционда төзелә торган мондый мөлкәтне сату-алу шартнамәсенең мөһим шарты булып сатып алучының күрсәтелгән йөкләмә шартларын үтәү бурычы тора.»;

1.2. 6.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.12. Гавами тәкъдим ярдәмендә сатуда җиңүче белән сату-алу килешүе төзү гавами тәкъдим ярдәмендә мөлкәтне сату йомгаклары турында беркетмә "Интернет" челтәрендәге рәсми сайтта урнаштырылган көннән алып ун көннән дә иртәрәк һәм егерме көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) белән, җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Якты күл авыл җирлеге Советы Рәисе** **З. З. Мөхтәров**